ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07. 12. 2018 г.Мензелинск № 1369

**Ордер комиссиясе турында**
**Нигезләмәне раслау турында**

Җир эшләрен башкару, төзекләндерү һәм Минзәлә муниципаль районының шәһәр территорияләре һәм авыл җирлекләрендәге торак пунктларның тышкы күренешен контрольдә тоту алымнарын һәм формаларын камилләштерү, нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Уставын кулланып,

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Ордер комиссиясе турындагы Нигезләмәне расларга (кушымта№1).
2. Ордер комиссиясе составын расларга (кушымта №2).
3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Д.А.Чухланцевка йөкләргә.

Җитәкче урынбасары А.Г.Гатина.

Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты
Җитәкчесе карарына
Кушымта№1
дата 07.12.18 № 1369

## Ордер комиссиясе турында Нигезләмә

### 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1.Җир эшләрен башкаруга ордерларны килештерү буенча ордер комиссиясе (алга таба – Комиссия) Минзәлә муниципаль районында җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын башкаруны тәэмин итү максатларында Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты каршында төзелгән даими гамәлдә булган орган булып тора.

1.2.Комиссия үз эшчәнлеген дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, инженер челтәрләрен (җылыту, суүткәргеч, газүткәргеч, канализация), кабель линияләрен, җир асты корылмаларын, яшел үсентеләрне, юлларны һәм трамвай юлларын эксплуатацияләүче оешмалар белән үзара бәйләнештә башкара.

1.3.Комиссия үз эшчәнлегендә җир асты коммуникацияләрен һәм корылмаларын кабаттан төзү һәм сузу буенча эшләрне башкару өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салучы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, Минзәлә шәһәрен төзекләндерү Кагыйдәләрен, авыл җирлекләрен төзекләндерү кагыйдәләрен, шулай ук гамәлдәге Нигезләмәне куллана.

### Комиссиянең төп функцияләре һәм бурычлары

2.1. Минзәлә муниципаль район территориясендә җир эшләрен башкаруга ордерларны вакытында һәм оператив яраштыру Комиссиянең төп функциясе булып тора.

2.2. Җир эшләрен башкарганда җир казу белән бәйле эшләрне тәртипкә салу, аварияләрне һәм бәхетсезлек очракларын булдырмау, шәһәрне төзек хәлдә тоту һәм яшелләндерү Комиссиянең төп бурычлары булып тора.

2.3. Комиссия йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында, үз компетенциясе чикләрендә территориянең санитар торышын, транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, йортлар ишегалларына, оешмаларга, шулай ук торак, хезмәт, сәүдә, уку, балалар биналарына керүне

төзү белән бәйле мәсьәләләрне карый һәм шәһәр территориясендә җир эшләрен башкаруга ордерлар бирә.

## 3.Комиссиянең эшен оештыру

3.1.Ордерларны яраштыру буенча Комиссия эше белән Комиссия рәисе җитәкчелек итә һәм аның утырышларын уздыра.

3.2.Комиссия сәркатибе:

- Комиссия утырышы беркетмәләрен рәсмиләштерә.

## 4.Комиссиянең эш тәртибе

4.1.Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары. Комиссия сәркатибе һәм Комиссиянең башка әгъзалары керә. Комиссия эше белән Комиссия рәисе җитәкчелек итә, ә ул булмаганда – Комиссия рәисе урынбасары.

4.2.Комиссия үз эшчәнлеген Комиссия утырышында кабул ителә һәм аның рәисе тарафыннан раслана торган эш планы нигезендә алып бара.

4.3.Комиссия утырышы атнага бер тапкыр чәршәмбе көннәрендә 9.00-10.00 сәгатьләрдә уздырыла.

4.4.Комиссиянең һәр әгъзасы ордерның әзерләнгән проектларын тикшерә, аннары ордерны яраштыру битендә язма калдыра.

Техник архивны куллану яисә урынга чыгу зарурлыгы туган очракта, Комиссия әгъзасы ордерның күчермәсен һәм график материалларны ала. Бу очракта Комиссиянең тиешле әгъзасы Комиссиянең алдагы утырышында ордерны яраштыру зарурлыгы турында язма калдыра.

Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты Җитәкчесе
карарына Кушымта №2
дата________________№

**Ордер комиссиясе составы**

| | | |
|---|---|---|
| Чухланцев Д.А | | Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары – Ордер комиссиясе рәисе |
| Басков Е.А. | | Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы –Ордер комиссиясе рәисе урынбасары |
| Петров В.К. | | Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район башкарма Комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы урынбасары – Ордер комиссиясе сәркатибе |
| Ордер комиссиясе әгъзалары | | |
| Ягафаров Р.Ф. | | Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәр Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге җитәкчесе |
| Шакиров Р.С. | | Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Финанс-бюджет һәм җир-милек палатасы рәисе урынбасары, җир-милек мөнәсәбәтләре бүлеге начальнигы |
| Габдрахманов Р.К. | | “Коммуналь челтәрләр” АҖ директоры |
| Яһудин И.Х. | | Чаллыгаз” ЭПУ АДС начальнигы (килешенү буенча) |
| Сизов А.Г. | | “Таттелеком” ПАО электр челтәренең Яр Чаллы зона узелы электр элемтәсенең район узелы начальнигы (килешенү буенча) |
| Гайсин Р.А. | | “Түбән Кама электр челтәрләре “Челтәрләр компаниясе” ААҖнең Минзәлә районы электр челтәрләрефилиалы начальнигы |
| Гайфуллин А.Г. | | “Минзәлә урманчылыгы” ДКУ җитәкчесе (килешенү буенча) |
| Губернаторов В.М. | | “Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтенең 15 отряды” федераль дәүләт казна учреждениесе 122 янгын часте начальнигы |